ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
ИСКЕ КОРМАШ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

423733, Иске Кормаш авылы,
Үзәк ур., 29 нчы йорт.
Тел.3-44-56

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ СТАРОКУРМАШЕВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АКТАНЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

423733, село Старое Курмашево,
ул. Центральная,дом 29,
Тел. 3-44-56

**КАРАР** **РЕШЕНИЕ**

**«17» сентябрь 2019 ел** **№ 22**

**Референдум үткәрү инициативасы турында**

12.06.2002 ел, № 67-ФЗ “Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында” гы Федераль законның 15 статьясы, 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 22, 56 статьялары, “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы “Җирле референдум турында” Татарстан Республикасы Законының 12, 17 статьялары, Актаныш муниципаль районының “Иске Кормаш авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставының 12 статьясы нигезендә, Актаныш муниципаль районы Иске Кормаш авыл җирлеге Советы

**карар чыгарды:**

1. Түбәндәге мәсьәлә буенча җирле референдум үткәрүне инициировать итергә:

"Сез 2020 елда үзара салымның бер тапкыр түләвен кертү белән килешәсезме 500 (биш йөз) сум, Иске Кормаш авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән, көндезге формада белем алучы студентлардан, 1 төркем инвалидлардан кала, алынган акчаны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия булган мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү турында:

- торак пунктларда су челтәрләрен ремонтлау, карап тоту, су чыганакларын ремонтлау һәм лицензияләү;
- Сабантуй үткәрү урыннарын төзекләндерү;
- рәсми физкультура-сәламәтләндерү һәм спорт чараларын оештыру һәм уздыру;
- авыл җирлеге территориясендә агач кисү;
- ритуаль хезмәтләр өчен инвентарь сатып алу;
- зират коймасын ремонтлау;
- Күмү урыннарын документаль рәсмиләштерү;
- юлларны ремонтлау һәм карап тоту (грейдерлау,кардан чистарту);
- янгын гидрантларын,янгын краннарын урнаштыру ;
- янгын җиһазларен сатып алу;
- торак пунктларда урам исемнәре һәм йорт номерлары булган күрсәткечләр урнаштыру;
- җирлек торак пунктында Игъланнар тактасы ясау һәм аларны урнаштыру;
- урамнарны яктырту электр челтәрләрен карап тоту.

“ӘЙЕ” “ЮК”

2. Әлеге карарны түбәндәге адреслар буенча урнаштырылган махсус мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән игълан итәргә: ТР, Актаныш муниципаль районы, Иске Кормаш авылы, Үзәк урамы 26 нчы йортта урнашкан МБУ “Иске Кормаш мәдәният йорты; ТР, Актаныш муниципаль районы, Иске Балтач авылы, Үзәк урамы 29 нчы йортта урнашкан авыл клубы; Яңа Балтач авылы, Үзәк урамы 3 нче йортта урнашкан җәмәгатҗ үзәге; Кыр-Каентүбәч авылы, Үзәк урамы 38 нче йортта урнашкан авыл клубы; Шәбезбаш авылы, Үзәк урамы 21 нче нчы йортта урнашкан авыл клубы, ТР, Актаныш муниципаль районы һәм Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Иске Кормаш авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Боерыкның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Авыл җирлеге башлыгы И.Ә. Кашбразиев